

Татарларыбыз, ике-бер булса да, борынгыдын килгән ат үрчетү белән шогыльләнә. Без Ләмберә районы Аксен авылында фермер, КФХ «Юлдаш»ны жи-тәкләгән Рафик Аяс улы Фетхулловнын атлар табуны барлыгын беләбез, Темников районы Большое Татарское Караево авылында КФХ житәкчесе Шәйхулла Шәмил улы Поздняков күп иттереп атлар үрчетә, Кочкурово районы Татар Ымызы – Татарский Умыс халкы электән-элек атлар үстерә. Ичалки районында атлар үрчетәләр. Ипподромы да бар, экскурсияләр дә оештыралар. Ковылкино районы Паньжа авылында гомер итүче Василий Васильевич Чукаров дигән фермер берничә дистә ел ат үрчетү белән шогыльләнә. Эшмәкәр Яна ел ялларында сәламәтлек, дәрт, күп унай эмоцияләр бүләк иткән атка атланып йорүләр оештырган.      Бу гажәеп хайваннар белән аралашу аны шулай мавыктырган ки, ул аларга буш вакытынын зур олешен багышлый. Василий Васильевич атларны чабышка әзерли. Районда рысак-юртак токымлы атларын чабышка әзерләүче бердәнбер заводчы. Гадәттә атлар ике копчәкле махсус экипажга жигеп сынала.

Василий Васильевичнын барлыгы 100 баш чиста токымлы (чистопородные) аты бар. Алар – американы (айгыры), француз (3 баш айгыры), рус һәм орлов рысак-лары, рус тяжеловозлары. Анын атлары Раменское, Тамбов шәһәрләрендә үткән ярышларда унышлы чыгыш ясыйлар. Үткән елнын 12нче сентябрендә Винск кушаматлы аты, Мәскәү үзәк ипподромы базасында узган йогерешләрдә катнашып, призлы урын алган.

Бу хужалыктагы атларнын барысы да чисталар, тәртиплеләр, ягымлылар. Аларнын гажәеп матурлыгыннан һәм боеклегеннән карашларынны алып булмый. Атлар - гажәеп хайваннар: акыллы, игелекле, аралашучан. Аларда махсус энергетика бара.

Алдан килешеп, кечкенә торкемнәр белән анын ат абзарларына барырга момкин. Ин кыюларына, инструктор житәкчелегендә, атларда йорү тәкъдим ителә. Хайваннар белән тыгыз аралашуга әзер булмаган кешеләргә, аларга карап сокланырга, атны ашатырга һәм сыйларга була – якты хисләр гарантияләнә.

Ботен доньяда ипотерапия популяр – атка атланып йорү юлы белән дәвалау. Бүген В.В.Чукаров атка атланып йорү методикасын белән тулы күләмдә шо-гыльләнә. Шул исәптән инвалид балалар белән атка атланып дәвалану момкинлекләре дә тудыра. Киләчәктә ул Мордовиядә ин зур ат клубы булдырырга жыена.

**Н.ХӘЛИЛ**